ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 сентября 2022 ел № 4429

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 пунктның 13 пунктчасы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3841 номерлы, 2019 елның 28 июнендәге 3288 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карар преамбуласында «РФ Баш дәүләт санитария табибының 2011 елның 28 июнендәге 84 номерлы Карары белән расланган «Зиратларны, җирләү билгеләнешендәге биналарны һәм корылмаларны урнаштыруга, булдыруга һәм карап тотуга карата гигиена таләпләре» СанПиН 2.1.2882-11» сүзләрен «РФ Баш дәүләт санитария табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать биналарын эксплуатацияләүгә һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар оештыруга һәм үткәрүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.1.3684-21» сүзләренә алмаштырырга;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибендә:

- 1 пунктта «РФ Баш дәүләт санитария табибының 2011 елның 28 июнендәге 84 номерлы Карары белән расланган «Зиратларны, җирләү билгеләнешендәге биналарны һәм корылмаларны урнаштыруга, булдыруга һәм карап тотуга карата гигиена таләпләре» СанПиН 2.1.2882-11» сүзләрен «РФ Баш дәүләт санитария табибының 2021 елның

28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать биналарын эксплуатацияләүгә һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар оештыруга һәм үткәрүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре» СанПиН 2.1.3684-21» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

1) якын туганнар – үсү һәм кимү ягына бара торган туры линия буенча туганнары (ата-аналары, балалары, бабайлары, әбиләре һәм оныклары), тулысынча туган һәм тулысынча туган булмаган (атасы яки анасы уртак булган) абыйлар (энеләр) һәм апалар (сеңелләр);

2) законлы вәкилләр – ата-аналар, уллыкка алучылар, опекуннар яки попечительләр;

3) каберлек – вафат булучыны җирләү өчен бирелгән җир участогындагы җирләү башкарылган кабер яисә көл салынган урнаны урнаштыру өчен бирелгән һәм көл салынган урна урнаштырылган колумбарий куышы;

4) җирләү өчен урын (җирләү урыны) – вафат булганнарның һәм һәлак булганнарның мәетен һәм көлен күмү өчен билгеләнгән, күмү билгеләнешендәге объект киңлегенең (зират, колумбарий һ. б.) бер өлеше;

5) җирләүләрне теркәү кенәгәсе – күмү урынында һәр җирләү турында мәгълүмат кертелә торган кенәгә. Җирләүләрне теркәү кенәгәсе катгый хисап документы булып тора һәм даими саклау срогы булган эшләргә карый (әлеге карарга 3 нче кушымта);

6) кабер өсте корылмасы – һәйкәл, стела, обелиск, тәре, чәчәклек, чардуган, плитә, бордюр ташы, җирләү урыны чикләрендә урнаштырылган һәм җирләү урынына нык бәйле башка предметлар, конструкцияләр, корылмалар;

7) зират – вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын), көлен күмү өчен билгеләнгән җирләү билгеләнешендәге объект, шулай ук үлгәннәрне күмүне һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән биналар, корылмалар һәм башка объектлар;

8) җирләү өчен җаваплы зат – вафат булучының теге яки бу урында җирләнү теләген үтәгән зат. Җирләү өчен җаваплы зат бер үк вакытта каберлек урнашкан җирләү урыны өчен дә җаваплы. Җирләү урыны өчен җаваплы затның бурычына күмелү урыны күләмен саклау, анда чисталыкны тәэмин итү керә;

9) туганнар кабере – вафат булучының якын туганы күмелгән кабер;

10) гаилә (нәсел) каберлеге – бер гаиләгә һәм (яки) нәселгә караган Россия Федерациясенең вафат булган гражданнарын җирләү өчен, закон нигезендә җәмәгать зиратында бирелә торган җир участогы;

11) җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт – җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән, вафат булганнарны җирләүне, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик зат;

12) көл салынган урна – вафат булучының көлен салып күмә торган савыт;

13) җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге – гамәлдәге законнар нигезендә җирләү буенча хезмәтләр исемлеген түләүсез нигездә күрсәтү;

14) күмү – йола һәм традицияләр нигезендә, үлгәннән соң кешенең гәүдәсен (мәетен) җирләү буенча йола гамәлләре;

15) вафат булучының теләге – шаһитлар катнашында телдән яки язма рәвештә белдерелгән теләк:

- патологоанатомик ярып карауга дучар ителергә ризалык яки риза булмау турында;

- аның тәненнән органнарны һәм (яки) тукымаларны алуга ризалык яки риза булмау турында;

- кремациягә дучар ителергә;

- теге яки бу затка үз теләген үтәүгә ышаныч турында;

- теге яки бу урында, теге яки бу йола яки традицияләр буенча, элек вафат булган теге яки бу затлар белән янәшә күмелү.

16) вафат булучының теләген үтәүче – аның теләк белдерүендә күрсәтелгән, аның ризалыгы белән вафат булучының теләген үтәү бурычын үз өстенә алган зат.

17) колумбарий – көл салынган урналарны күмү (саклау) урыны;

18) эксгумация – суд-медицина яки криминалистика экспертизасы өчен яки кабат җирләү өчен, вафат яки һәлак булган затның мәетен, калдыкларын җирләнгән урыннан алу.»;

- 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Яр Чаллы шәһәре зиратлары җирләүне гамәлгә ашыру буенча өч типка бүленергә мөмкин: ачык, ирекле җирләү өчен ябык һәм ябык.

Ачык зиратлар – җирләү чикләүләрсез гамәлгә ашырыла торган яңа җирләү урыннары булдыру өчен җир участоклары булган зиратлар.

Ирекле җирләү өчен ябык зират – яңа җирләү урыннары булдыру өчен буш җир участоклары булмаган, ә гамәлдәге каберләрдә урыннар булганда җирләү гамәлгә ашырыла торган зиратлар.

Ябык зиратлар – вафат булганнарны җирләү гамәлгә ашырылмый торган зиратлар.

Зиратның статусы турындагы карар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

Зиратларны төзекләндерү, аларны тиешле тәртиптә карап тоту, җирләүнең санитария нормаларын үтәү, закон таләпләре нигезендә, Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

- 28 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

- 29 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

- 32 пунктта «җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәткә» сүзләрен «вәкаләтле органга» сүзләренә алмаштырырга;

- 57 пунктның бишенче абзацында «мөрәҗәгать иткәннән соң бер тәүлектән артмаган срокта» сүзләрен «мөрәҗәгать иткән көнне» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 57.1-57.3 пунктлар өстәргә:

«57.1. Җирләүгә рөхсәт гариза бирүчегә ул мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Җирләүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карар нигезле булырга һәм мондый баш тарту нигезен үз эченә алырга тиеш.

57.2. Түбәндәге очракларда гариза бирүчегә җирләү өчен рөхсәт бирүдән баш тартыла:

1) гариза бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 57 пунктында каралган документлар тапшырылмау яисә тулы булмаган күләмдә тапшырылу;

2) гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән җәмәгать зиратында җирләү өчен урыннар булмау.

Башка очракларда гариза бирүчегә (аның вәкиленә) җирләү өчен урын бирүдән һәм әлеге урында җирләүгә рөхсәт бирүдән баш тарту рөхсәт ителми. Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) җирләүгә рөхсәтсез җирләү өчен урын яисә җирләү өчен урын бирмичә җирләүгә рөхсәт бирү рөхсәт ителми.

57.3. Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә җирләүне теркәү һәм җирләү турында таныклык бирү вафат булучыны җирләү процедурасы тәмамланганнан соң башкарыла»;

- 70 пунктта «, сатулар нәтиҗәсе буенча, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә торган» сүзләре үз көчен югалткан дип танырга;

- 72 пунктта «Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан зиратлар территориясендә теркәлгән һәм эшләп килүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләрне килешү нигезендә җәлеп итеп,» сүзләре үз көчен югалткан дип танырга;

- 86, 87 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«86. Яр Чаллы шәһәре зиратларында кабер өсте корылмаларын урнаштыру әлеге тәртиптә каралган шартларга һәм гамәлдәге норматив актларга туры китереп гамәлгә ашырыла.

87. Каберләргә кабер өсте корылмалары (кабер ташлары, чардуганнар, чәчәклекләр), җирләү урыны өчен җаваплы зат тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылганда, вәкаләтле орган белән килештереп урнаштырыла яки башкага алмаштырыла:

- кабер өсте корылмасын урнаштыруга яки алмаштыруга гариза;

- җирләү урыны өчен җаваплы затның паспорт күчермәсе;

- җирләү турында таныклык күчермәсе;

- кабер өсте корылмасының проекты (эскизы, фотосурәте, тасвирламасы);

- кабер өсте корылмаларын әзерләүгә яки сатып алуга документ күчермәсе.

Урнаштыру технологиясе үтәлмәү урнаштырылган кабер өсте корылмаларына, инженерлык челтәрләренә, аллея, юллар өслегенә, яшел утыртмаларга һәм башка тышкы төзекләндерү объектларына зыян (бозылу, юкка чыгарылу) китергән очракта, заказчы вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән кимчелекләр акты нигезендә, китерелгән зыянны тулы күләмдә капларга тиеш.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 87.1 пункт өстәргә:

«87.1. Кабер өсте корылмасын урнаштыруны (алмаштыруны) килештерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;

2) тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 87 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;

3) урнаштырыла яки алмаштырыла торган кабер өсте корылмасының проекты әлеге Тәртипнең 7 бүлегендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү.»;

- 91 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

- 99 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

- 100 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) кабернең торышы турында акт төзү өчен Вәкаләтле орган, җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительлек советы вәкилләре катнашындагы комиссияне чакырырга;»;

- 101 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«101. Кисәтелгәннән соң бер ел узуга кабер тәртипкә китерелмәгән һәм кызыксынучы зат гамәлдәге җирләү урыны өчен җаваплылыгын раслаучы документаль дәлилләрне тапшырмаган очракта, Вәкаләтле орган җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительлек советы вәкилләре белән берлектә, каберне һәм кабер өсте корылмасын хуҗасыз дип тану турында акт төзергә хокуклы.»;

- 107 пунктның 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 107.1 пункт өстәргә:

«107.1. Зиратка килүче инвалидлар, таныклык күрсәтеп, зират администраторыннан пропуск алган очракта, зират территориясенә автотранспорт чарасы белән керергә хокуклы.»;

- 109 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт өстәргә:

«13) махсус автотранспорттан (катафалк транспорт чарасы), зират территориясен чистарту, су ташу, чүпле контейнерлар (чүп) чыгару өчен транспорт чарасыннан, шулай ук 107.1 пунктта каралган очрактан тыш, шәхси автомобильләрдә керү.»;

3) 1 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

4) 2 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

5) 7 нче кушымтаны 3 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 сентябрендәге
4429 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә ритуаль
хезмәтләрне оештыру һәм җирләү
урыннарын карап тоту тәртибенә
1 нче кушымта

КҮМҮ (ҖИРЛӘҮ) ӨЧЕН ГАРИЗА

№_____ «______»_________20 ____ ел

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгына _________________________________

кемнән _______________________________________________________________________________

(вафат булучыны җирләүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вафат булучыга карата туганлык яки башка мөнәсәбәтен күрсәтергә)

паспорт, телефон_______________________________________________________________________

(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән, теркәлү һәм фактта яшәү адресы, элемтә өчен шәхси телефон)

_______________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________

_________________________________________________________________ зиратында

(зиратның исеме)

вафат булган __________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме баш килештә)

туу датасы ________________________ үлү датасы _____________________________

үлү турында таныклык_______________ серия ______№_______

(бирү датасы)

□ яңа урында;

□ туганнар белән күмелә торган буш урында;

□ ________ елда ____________________________________ участокта № _____ кварталда инв. №____ ____________ кабердә җирләнгән (Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә) ____________ _____________________________________________________________________________ язылган _______________________________________________________________________ урнаштырылган

(кабер ташының төрен яки тану билгесен күрсәтергә)

вафат булган ____________________________________________________________ кабердә

(фамилиясе, исеме, атасының исеме баш килештә)

җирләүне (янәшә җирләүне) сорыйм.

(кирәклесенең астына сызарга)

ИСКӘРМӘ:

1. Вафат булучыны җирләүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алучы үз өстенә йөкләмә ала: рөхсәттә күрсәтелгән вакытта зиратка керүне гамәлгә ашырырга, җир эшләрен һәм хезмәтләр комплексын профессиональ рәвештә башкарырга, җирләү урынын һәм аның янәшәсендәге территорияне карап тотарга, күрше каберләргә һәм кабер өсте корылмаларына зыян китерү һәм үтәмәгән өчен милек җаваплылыгы алырга.
2. Җир эшләрен башкарганда куркынычсызлык техникасын, гамәлдәге регламентларны һәм нигезләмәләрне, САНПИН таләпләрен төгәл үтәргә, махсус өйрәтелгән җир казучылар белән эшләргә кирәк.
3. Җирләү өчен җир участогын үз белдегең белән арттыру, һәйкәлләрне һәм башка кабер өсте корылмаларын (чардуганнарны), мемориаль такталарны вәкаләтле орган рөхсәтеннән башка урнаштыру, үзгәртеп кору һәм алу, чүп калдыру тыела.

Минем тарафтан бирелгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм, искәрмә белән таныштым, гаризага түбәндәгеләрне терким:
- үлү турында таныклык; Бөек Ватан сугышы ветераны, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы таныклыгы (булса), җирләү турында таныклык, минем паспорт күчермәсе, җирләүне башкаручы юридик затны (шәхси эшмәкәрне) дәүләт теркәве турында таныклык. Шулай ук гаризага, гаризаның аерылгысыз өлеше булган персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм анкетаны (1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта) терким.

Гариза бирүченең шәхси имзасы ____________________ «____»____________________20___ ел

ВӘКАЛӘТЛЕ ОРГАН КАРАРЫ

_________ участокта №_____ кварталда күләме ___________(метрларда) булган җир бирелде.

Җирләү өчен зиратка керү датасы һәм рөхсәт ителгән вакыт ____________________

Җирләү өчен рөхсәт бирәм ______________________/______________________/

Җирләү башкарылды ____________________/______________________/

Кимчелекләр

______________________________________________________________________________

Җирләү турында бирелде (таныклыкка билге ясалды) №_________ ____________________

Гаризага 1 нче кушымта

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

(затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклаучы төп документның номеры, күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, атап йткәндә, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга: җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (тапшыруга), дәүләт һәм муниципаль органнарның рәсми запросы буенча мәгълүматлар: гариза бирүченең фамилиясе, яшәү урыны (теркәлү буенча, факттагы) адресы; өй телефоны; мобиль телефоны; вафат булган туганы, аның күмелү урыны турында мәгълүматлар һәм законнар һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешен тәэмин итү максатларында персональ мәгълүматларга караган башка мәгълүматлар җибәрүгә ризалыгымны белдерәм.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты: ул имзаланган вакыттан башлап һәм эшкәртү максатларына ирешкәнгә кадәр. Алга таба – Россия Федерациясендә Архив эше турындагы законнар нигезендә.
Әлеге ризалык, язма рәвештәге гариза нигезендә, минем тарафтан кире алынырга мөмкин

Гариза бирүченең шәхси имзасы _________________________«_____» _________20__ел

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы
вазыйфаларын башкаручы

Л.Р. Абдуллина

Башкарма комитетның
2022 елның 1 сентябрендәге
4429 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә ритуаль
хезмәтләрне оештыру һәм җирләү
урыннарын карап тоту тәртибенә
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең шәһәр хуҗалыгы
һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе
башлыгына
_____________________/___________________
_________________________________________
_________________________________________
_________________________________________
(кемнән: Ф.И.А.и., теркәлү адресы, элемтә телефоны)

Паспорт ________________________________
_________________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

ГАРИЗА

«____» ______ 20 ____ елда вафат булган, ___________________________________ җирләнгән,
(җирләү урыны)

_________________________________________________________________________________
(вафат (һәлак) булучы белән туганлык дәрәҗәсе, вафат булучының Ф.И.А.и.)

_____________________________________________________________________________ сәбәпле
(кабат җирләү сәбәбе, нигезе)

_________________________________________________ кабат җирләүне килештерүне сорыйм.
(кабат җирләү урыны)

Кабат җирләүгә каршы булган башка туганнар юк.

Бирелә торган мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен тулы җаваплылыкны үз өстемә алам.

Кушымта:
1) __________________________________________________________________;
2) __________________________________________________________________.

«___» ______ 20 ___ ел ________________ ________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ____________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклаучы төп документның номеры, күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, атап йткәндә, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга: җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (тапшыруга), дәүләт һәм муниципаль органнарның рәсми запросы буенча мәгълүматлар: гариза бирүченең фамилиясе, яшәү урыны (теркәлү буенча, факттагы) адресы; өй телефоны; мобиль телефоны; вафат булган туганы, аның күмелү урыны турында мәгълүматлар һәм законнар һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешен тәэмин итү максатларында персональ мәгълүматларга караган башка мәгълүматлар җибәрүгә ризалыгымны белдерәм.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты: ул имзаланган вакыттан башлап һәм эшкәртү максатларына ирешкәнгә кадәр. Алга таба – Россия Федерациясендә Архив эше турындагы законнар нигезендә.
Әлеге ризалык, язма рәвештәге гариза нигезендә, минем тарафтан кире алынырга мөмкин

Гариза бирүченең шәхси имзасы _________________________«_____» _________20__ел

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина

Башкарма комитетның
2022 елның 1 сентябрендәге
4429 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә ритуаль
хезмәтләрне оештыру һәм җирләү
урыннарын карап тоту тәртибенә
7 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең шәһәр хуҗалыгы
һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе
башлыгына
____________________/__________________
_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________
(кемнән: Ф.И.А.и., теркәлү адресы, элемтә телефоны)

Паспорт ______________________________
_______________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

ГАРИЗА

________________________________________________________________ җирләнгән урында
(үлүченең Ф.И.А.и.)

________________________________________________ урнаштыруны килештерүне сорыйм
(кабер өсте корылмасының исеме)

№ _________/_________/________
(җирләү кварталы/секторы/участогы)

________________________________________________________________________________
(зиратның исеме)

Кабер өсте корылмасын урнаштыру буенча эшләрне башкарачаклар:

1) ________________________________________________________________________;
(Ф.И.А.и., юридик затның исеме, адресы)

2) ________________________________________________________________________.
(Ф.И.А.и., юридик затның исеме, адресы)

Кушымталар:

1) Паспорт күчермәсе;
2) Җирләү турында таныклык күчермәсе;
3) Кабер өсте корылмасының проекты (эскизы, фотосурәте, тасвирламасы).

«___» ________ 20__ ел     _________________     _________________
(гариза бирүче имзасы)     (имза расшифровкасы)

Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәсе:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

«____»_____________20____ ел

____________________ ____________________ ____________________

(вазыйфа) (имза) (имза расшифровкасы)

М.У.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның шәхесен таныклаучы төп документның номеры, күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, атап йткәндә, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга: җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (тапшыруга), дәүләт һәм муниципаль органнарның рәсми запросы буенча мәгълүматлар: гариза бирүченең фамилиясе, яшәү урыны (теркәлү буенча, факттагы) адресы; өй телефоны; мобиль телефоны; вафат булган туганы, аның күмелү урыны турында мәгълүматлар һәм законнар һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешен тәэмин итү максатларында персональ мәгълүматларга караган башка мәгълүматлар җибәрүгә ризалыгымны белдерәм.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты: ул имзаланган вакыттан башлап һәм эшкәртү максатларына ирешкәнгә кадәр. Алга таба – Россия Федерациясендә Архив эше турындагы законнар нигезендә.
Әлеге ризалык, язма рәвештәге гариза нигезендә, минем тарафтан кире алынырга мөмкин

Гариза бирүченең шәхси имзасы _________________________«_____» _________20__ел

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина